Казан шәһәре Мәскәү районы
“Ф.Аитова исемендәге татар телендә белем бирүче 12 нче гимназия” МББУ

| “Каралды” | “Килешенде” | “Расланды” |
|---|---|---|
| Методик берләшмә җитәкчесе: | Тәрбия эшләре буенча директор | Гимназия директоры: |
| ________/ Хуҗина Р.Т. | урынбасары ________/ Рәхмәтуллина З.Н. | ________/ Нәгыймова З.Ш. |
| Беркетмә №1 | | Боерык №149 |
| “_24_” август 2020ел | “_24_” август 2020 ел | “_24_” август 2020 ел |

**“Әдәбият дөньясында”**
**өстәмә белем бирү берләшмәсенең**
**ЭШ ПРОГРАММАСЫ**

Төзүчесе: Насыйбуллина Гөлнур Зәкәрия кызы,
өстәмә белем бирү педагогы

**2020 ел**

**“Әдәбият дөньсында” түгәрәгенең эш программасы**

Илебез мәгариф системасында укыту эшчәнлеген яңарту процессы барган вакытта мәктәп өстенә тирән белемле, әхлаклы, зыялы шәхес тәрбияләү бурычы куела. Ана телен һәм әдәбиятын укыту программасында әдәбият дәресләрендә язучылар иҗатын өйрәнүгә бик аз урын бирелгән. Ә әдипләр иҗаты бигрәк тә егерменче гасыр татар әдәбиятында зур урын алып тора. Укучыларга рухи, милли һәм әхлак тәрбиясе бирүдә, аларны халкыбызга хезмәт итәрдәй шәхес буларак формалаштыруда бу курста өйрәнеләчәк әдипләрнең әсәрләре роле зур. Аларны укучыларга тәкъдим итү, бергәләп анализлау тормышта укучыга үз урынын табарга ярдәм итәр дигән фикердән чыгып, теоретик мәгълүматлар практик эшләр белән ныгытылып бару каралды.

Программада төрле дәрес формалары бирелгән: дәрес-презентация, дәрес-конференция, очрашу дәресләре, дәрес-лекция, дәрес-әңгәмә, дәрес-зачет, дәрес-бәхәс.

Дәрестә укучы эшчәнлеге билге белән бәяләнми. Нәтиҗәләр укучыларның иҗади эшләре һәм зачетлар белән бәяләнә.

“Әдәбият дөньясында” түгәрәк программасы 5 нче сыйныфлар өчен төзелде.

Үткәрү вакыты атнасына 2,15 сәг. исәбеннән 35 атнага төзелгән. Барлыгы 70 дәрес. Бер занятиенең вакыты 1сәг. 10 минут

**Программаның максаты**

Танылган әдибләребезнең иҗатлары аша язучы һөнәре серләренә төшендереп, аның үзенчәлекләре һәм нечкәлекләре белән таныштыру, фәнгә карата кызыксыну уяту аша, эзләнүчән шәхес формалаштыру.

**Программаның бурычлары**

1. Балаларда матур әдәбият әсәрләрен укуга, китапка кызыксыну һәм язучы һөнәренә хөрмәт тәрбияләү.
2. Әсәрне өйрәнү процессында укучыларның бәйләнешле сөйләмен, фикерләү сәләтләрен үстерү, иҗат активлыкларын киңәйтү
3. Әдәби геройлар үрнәгендә укучыларга эстетик зәвык, милли үзаң, әхлак тәрбиясе бирү, аларны зур тормышка әзерләү.4.
4. Күренекле татар әдипләре һәм аларның әсәрләрен үзләштерүләренә ирешү.

**Программаның эчтәлеге**

1. Түгәрәккә йөрүчеләрне барлау. Еллык эш планы, максатлар һәм бурычлар белән таныштыру. Инструктаж үткәрү (1 сәг.)
2. Халык авыз иҗаты. Фольклор , аның жанрлары.Әкиятләр. Андагы фантастик, тылсымлы сюжетлар.Яхшылык һәм явызлык көрәше.
3. Татар халык әкиятләре” китабы белән танышу. Таңбатыр”, “Солдат балтасы” әкияләрен укып өйрәнү.Текстка якын ите, балалардан сөйләтү. Кабатлаганда, детоьләргә игътибар итү.Әкият героеның сыйфатлары.(10 сәг.)
4. Мәзәкләр.Алардагы тапкырлык, юмор,кимчелекләрне тәнкыйтьләү, тирән мәгънә, хикмәтлелек. 7 сәг.)

5 . К. Насыйри. Хикәяләр. (“ Иске мәдрәсәдә”,”Патша белән карт”, “Аңгыралык бәласе”. Әйтергә теләгән фикернең кыска һәм аңлаешлы
итеп бирелүе (2 сәг.)

6. Ф. Әмирхан”Нәҗип”. Хикәянең сюжеты. Нәҗип кичерешлренең самимилеге, кичерешләрендәге борылышлар. Хикәя турында теоретик материал.(4 сәг.)

7. Г. Кутуй “Рөстәм маҗаралары”Язучының тормыш хәле. Фашистларга каршы көрәшнең фантастик маҗара стилендә бирелеше. Рөстәмнең характер сыйфатлары.Фантастик әкиятләр белән бу әсәр арасындагы уртаклык һәм аермалар.(5 сәг.)
8. Р. Сабитов.  “Ярсулы яз”хикәясе. Мәктәп тормышының үзенчәлекле детальләрдә чагылуы. Укучы һәм укытучы мөнәсәбәтен, табигатьне бала күңеле һәм хисләре аша тасвирлау. Телнең сурәтлелеге.(4 сәг.)
9. А. Расих. Язучының кыскача тормыш хәле белән таныштыру. “Хәвефле сынау” повесте. Әсәрдә маҗаралылык, реаль чынбарлыкны чагылдыру үзенчәлекләре, маҗаралы жанр турында гомуми мәгълүматны бирү.(4 сәг.)
10. И. Гази. Тәрҗемәи хәле. “Мәүлия нигә көлде”, “Өч Мәхмүт” хикәяләре. И. Газиның хикәя иҗат итүдәге осталыгы, сурәтләрнең тыгызлыгы, лирик, юмористик төсмерләргә байлыгы, гыйбрәтле хәлләрнең яктыртылуы, характерлар аныклыгы.(8 сәг.)
11. Ч. Айтматов “Беренче мөгаллим” . Мәгърифәтне зурлау мотивларының көчле чагылышы. Дүшән һәм Алтынай образлар. Әсәрдә тугандаш кыргз халкыныңгореф-гадәтләре чагылышы.(5 сәг.)
12. Р. Сабитов.” Ярсулы яз” хикәясе мәктәп тормышында үзенчәлекле детальләрдә чглуы. Укучы һәм укытучы мөнәсәбәтләрен , табигатҗне бала күңеле һәм хисләреаша тасвирлау. Телнең сурәтлелеге.(4 сәг)
13. А. Расих “Хәфевле сынау”повесте. Әсәрдә маҗаралылык, реаль чынбарлыкны чагылдыру үзенчәлекләре. Маҗарал ы жанр үзенчәлекләре.(4 сәг.)
14. Т. Миңнуллин” Авыл эте Акбай”пьесасы. Хайван образлары артында кеше лек сыйфатлары ятуын ачыклау. Образларнң үзенчәлекле сйфатлары. Төрле мөнәсәбәтләрнең һәм мөгаләмәләрнең кызыклы ситуациядә ачылуы.(9 сәг.)
15. Л. Иксанованың “Наил һәм Фаил” әсәрен укып өйрәнү. Язучының тормыш һәм иҗат юлы белән таныштыру. Үзәк геройның шуклыгы, хаталары , холкы. Фаилнең иптәшләре (4 сәг.)
16. Төрле чаралар- 1

**“Әдәбият дөньясында” ”түгәрәге эшчәнлегенең    көтелгән  нәтиҗәләре:**

- проблеманы аңлап  гипотеза чыгару, үз фикереңне дәлилләр  китереп раслый  белү, телдән (диалогик, монологик) һәм язма сөйләмдә сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен аерып алу, нәтиҗәләрне формалаштыру;
- үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәле булуына ирешү, үз эшчәнлегеңне контрольгә алу;
- укытучы белән бергәләп, үз эшен, иптәшләренең җавапларын бәяләү;
- кагыйдә, күрсәтмәләрне истә тоту һәм аларга ияреп гамәлләр кылу;
- эшләнгән эшкә бәя бирү, сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү.
- аерым төр һәм жанрга караган әсәрләрне аңлап укый һәм кабул итә, эчтәлеген кабатлап (аерым очракларда текстны яттан) сөйли, кирәк чакта тексттан өзекләр китерә алуга ирешү;
- укыган әдәби әсәрнең эчтәлеген, темасын, проблемасын, идеясен билгели, геройларын һәм әдәби дөньясын бәяли алуына, аның нинди төр һәм жанрга каравын аеруына ирешү;
- укучының классик әдипләрнең тормыш һәм иҗат юлларының төп фактларын белүе;
- әдәби текстның мәгънәви өлешләрен аерып чыгарып, укыган буенча тезислар һәм план төзү, геройларга характеристика бирү, сюжет, композиция үзенчәлекләрен, махсус сурәтләү чараларының ролен билгеләү күнекмәсе булдыру;
- диалог төзүдә һәм коллектив фикер алышуда катнашу;
- сыйныфташлары һәм  укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү;
- төрле фикерләрне исәпкә алып эш итү;
- үз фикерен дәлилле белү, тормыштан мисаллар китерү;
- төрле җавапларны тыңлау, чагыштыру, нәтиҗә ясау;
- үз фикерен тулы һәм төгәл итеп әйтә белү;
- күмәк эш вакытында уртак фикергә килү;
- мәгълүмат туплауда үзара хезмәттәшлек итүдә инициативасы күрсәтү;
- укылган текстлар буенча сораулар бирә алу.

**Түгәрәкнең тематик планы**

| № | Занятиенең темасы | занятие саны | Эш төре |
|---|---|---|---|
| 1 | Түгәрәккә йөрүчеләрне барлау. Еллык эш планы, максатлар һәм бурычлар белән таныштыру. Инструктаж үткәрү | 2 | әңгәмә |
| 2 | Халык авыз иҗаты. Фольклор, аның жанрлары | 2 | презентация |
| 3 | Фольклор тупланган китаплар күргәзмәсе белән танышу (китапханәдә) | 2 | Дәрес- экскурсия |
| 4 | Татар халык әкиятләре" китабы белән танышу | 2 | киапханәдә |
| 5-6 | Таңбатыр" әкиятен уку, аны анализлау | 2 | Дәрес- бәхәс |
| 7-8 | "Солдат балтасы" әкиятен укып өйрәнү, анализлау | 2 | Дәрес- бәхәс |
| 9 | Әкиятләргә хас сыйфатлар турында тест сораулары төзү. | 2 | Практик дәрес |
| 10-11 | "Без әкият язабыз" . Әкият язу. Иң яхшыларын гимназия газетасына тәкъдим итү | 2 | Дәрес- конкурс |
| 12 | Мәзәк жанры белән танышу. | 2 | презентация |
| 13-14 | Мәзәкләр китабыннан мәзәкләр уку, анализлау | 2 | презентация |
| 15-16 | Үзләре чыгарган, әти- әниләреннән ишеткән мәзәкләрдән "Мәзәкләр" журналы чыгару | 2 | практик |
| 17 | Мәзәкләргә хас сыйфатларны ачыклау өчен тест сораулары төзү. | 2 | практик |
| 18-19 | К. Насыйриның " Хикәяләр" китабыннан мәзәкләр уку, анализлау. Нәтиҗәләр чыгару | 2 | Бәхәс- дәрес |
| 20 | "Иң оста мәзәк сөйләүче" кичәсен оештыру | 2 | Дәрес- конкурс |
| 21-22 | Фольклор жанрының башка төрләре турында реферат язарга өйрәтү | 2 | практик |
| 23-24 | Фольклор жанрының башка төрләре турындагы рефератлар буенча чыгышлар | 2 | практик |
| 25-26 | Ф. Әмирхан "Нәҗип" хикәясен уку, анализлау | 2 | Дәрес- конференция |
| 27-28 | "Нәҗип" хикәясен сәхнәләштерү | 2 | практик |
| 29-31 | Г. Кутуй "Рөстәм маҗаралары" әсәрен уку, анализлау | 3 | Дәрес- конференция |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 32-33 | Фантастика жанрына хас сыйфатларны барлау. Фантастик хикәя язып карау | 2 | практик |
| 34 | К. Тинчурин театрына сәяхәт | 2 | Дәрес-экскурсия |
| 35-37 | Р. Сабитов. “Ярсулы яз” әсәрен уку, анализлау | 3 | Дәрес-конференция |
| 38 | Темалар сайлау һәм “Ярсулы яз” хикәясе буенча фәнни эш язу. | 2 | практик |
| 39-41 | А. Расихнң “Хәфевле сынау” әсәрен укып өйрәнү, анализлау. | 3 | Сөйләм телен үстерү |
| 42 | “Хәфевле сынау” әсәре буенча тест сораулары төзү | 1 | Дәрес- зачет |
| 43-45 | И. Гази. “Мәүлия нигә көлде”” хикәясен укып өйрәнү | 3 | Әңгәмә, бәхәс |
| 46 | Төрле ышанулар, аларның нәтиҗәләре турында әңгәмә | 1 | презентация |
| 47-49 | И. Гази. “Өч Мәхмүт” хикәясен укып өйрәнү. Уңай һәм тискәре геройларны билгеләү. Аларга характеристика бирү | 3 | Әңгәмә, бәхәс Дәрес-конференция |
| 50 | “Бәхет –нәрсә ул ?“ темасына сөйләшү | 2 | Сөйләм үстерү |
| 51-54 | Ч. Айтматовның “Беренче мөгаллим”әсәрен укып өйрәнү һәм анализлау. | 4 | Презентация, әңгәмә |
| 55 | “Беренче мөгаллим” видеофильмын карау. | 2 | практик |
| 56-59 | Т. Миңнуллинның ” Авыл эте Акбай”пьесасын укып өйрәнү. Геройларга характеристика бирү | 4 | Бәхәс Дәрес-конференция |
| 60-61 | Т. Миңнуллин” Авыл эте Акбай” пьесасы буенча куелган видеофильмны карау | 2 | практик |
| 62-63 | ” Авыл эте Акбай” пьесасы буенча кайбер пәрдәләрне сәхнәләштерү | 2 | практик |
| 64 | Т. Миңнуллинның мемориаль залында уен- квест | 2 | |
| 65-68 | Л. Иксанованың “Наил һәм Фаил” әсәрен укып өйрәнү | 4 | Әңгәмә, бәхәс |
| 69 | Г. Камал театрына сәяхәт | 2 | Дәрес- сәяхәт |
| 70 | Өйрәнелгән әдәби әсәрләр турында тест сорауларына җавап бирү. Йомгаклау дәресе. | 2 | Зачет- дәрес |
| | Барлык занятиеләр саны | 144 | |
| | Вакыты | 2,15 | |

**Әдәбият**


1. “Балалар фольклоры”. – Казан: “Мәгариф” нәшр., 2008
2. Исәнбәт Н. Отканга – мәкаль, тапкырга – табышмак. . – Казан:  Тат. кит. нәшр., 1973
3. Кәримуллин Ә. Китап дөньясына сәяхәт. – Казан:  Тат. кит. нәшр., 1979
4. Татар драматургиясе.- Тарих-2003, 22 том
5. Татар баллалар әдәбияты.-Тарих-2003, 19 том